| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Казан ш. №568-147/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Алабуга» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга, ташландык су агызуга һәм ташландык су агызуга (өслектәге агынты сулар) тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 №10-158/кс карарына үзгәрешләр кертү һәм ташландык су агызуга һәм ташландык су агызуга (өслектәге агынты сулар) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №10-158/кс карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 елга төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 ноябрендәге 38-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 12.09.2022 №1188 карары белән Алабуга шәһәрен су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу схемасына кертелгән үзгәрешләр нигезендә, 2023 елга ташландык су агызуга, ташландык су агызуга

(өслектәге агынты сулар) озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга, ташландык су агызуга һәм ташландык су агызуга (өслектәге агынты сулар) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 №10-158/кс карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «эчә торган суга,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «эчә торган суга,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «эчә торган суга,» һәм «салкын су белән тәэмин итү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «салкын су белән тәэмин итү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтада:

атамасында «салкын су белән тәэмин итү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №10-158/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2022 №568-147/кс-2022 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен ташландык су агызуга һәм ташландык су агызуга (өслектәге агынты сулар) 2019-2023 елларга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су (өслектәге агып җыелган суларны) агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Алабуга муниципаль районы | | | |
| 1 | «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 55,58 | 27,83 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 58,81 | 29,49 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 58,81 | 29,49 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 60,57 | 30,68 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 60,57 | 30,68 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 61,78 | 30,99 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 61,78 | 30,99 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 62,95 | 32,14 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 68,62 | 35,03 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге